***Гомәров И.Г.***

# XIX ГАСЫР ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА СӘЯХӘТНАМӘ ЖАНРЫ

Урта гасыр татар әдәбияты тарихында реаль-тарихи вакыйгаларны чагылдырган әсәрләр аз түгел. Бу төр әдәби ядкярләр авторның үзе күргән яисә катнашкан вакыйгаларны төгәл сурәтләргә омтылышы белән аерылып торалар. Эчтәлек һәм форма, жанр үзенчәлекләре җәһәтеннән аларны публицистик очерклар дип атап булыр иде. Мондый әсәрләр арасында юлъязмалар, ягъни сәяхәтнамәләр күпчелек өлешне тәшкил итәләр.

Жанр төре буларак сәяхәтнамәләр иң борынгы чорларга барып тоташа. Дөнья сүз сәнгате тарихында Геродот (б.э.к. V гасыр), Ибн Фадлан, Ибн Рөстә (X гасыр), Марко Поло (1245-1303), Ибн Батута (1304-1377), Афанасий Никитин (XV йөз), Исмәгыйль Бикмөхәммәд улы, Данеэль Дефо, Лоренс Стерн (XVIII гасыр) һәм башка бик күп сәяхәтче әдипләр иң беренче чиратта үзләренең бу жанрда иҗат ителгән әсәрләре белән мәгълүм затлар.

Жанр үзенчәлекләре ягыннан карaганда, сәяхәтнамәләрнең синкретик характерда булуы ачык күренә. Аның әлеге сыйфаты хакында Н.Г.Чернышевский: “Сәяхәтнамә үзендә тарих, статистика, фән элементларын берләштерә... Ул аерым шәхеснең чит кешеләр белән очрашуы нәтиҗәсендә туган уй-фикерләрен, хисләрен һәм маҗараларын иң җиңел формада үтә кызык һәм мавыктыргыч итеп тасвирлый ала. Сәяхәтнамә ул – бер үк вакытта роман да, анекдотлар җыентыгы да, тарих та, сәясәт тә”, – дип язган иде [1, 222].

Гасырлар дәвамында сәяхәтнамәләр тормыш ихтыяҗлары белән бәйләнештә үсә, үзгәрә баралар. Европа әдәбиятына күз салсак, әлеге жанрның төп ике юнәлештә үсешен күзәтергә мөмкин. Беренче юнәлештә туган әсәрләргә авторның үз күргәннәрен төгәл сурәтләргә тырышуы, тормыш чынбарлыгын барлык төсләре белән, реаль картиналар аша тасвирлавы хас. Мондый юлъязмаларда язучыны, иң беренче чиратта, реаль тормыш, тарихи, географик, этнографик фактлар кызыксындыра. Аның төп максаты – укучыны әлеге мәгълүматлар белән коралландыру, мәгърифәтле итү. XVIII гасырның беренче яртысында иҗат иткән инглиз язучылары Дефо, Свифт, Смоллет сәяхәтнамәләре, француз әдибе Дюпатиның 1785 елда язылган “Италиягә сәяхәт” әсәре нәкъ менә шундыйлардан.

Икенче төр юнәлештә язылган әсәрләрнең үзәгендә реаль тормыш картиналары гына түгел, ә язучының аларга карата мөнәсәбәте, аларны субъектив рәвештә кабул итү нәтиҗәсендә туган уй-хисләре, күңел кичерешләре чагылыш таба. Мондый сәяхәтнамәләргә хис-тойгы ташкыны, ягъни сентиментальлек хас. Әлеге юнәлешнең классик үрнәген тудыручы

инглиз әдибе Лоренс Стерн үз әсәрен нәкъ шулай – “Сентименталь сәяхәт” (1768) дип атый да. Бу әсәрдә беренчел момент – сәяхәт үзе түгел, ә авторның сәяхәт итү вакытында туган хис-кичерешләре, эчке дөньясы.

XVIII-XIX гасыр рус әдәбиятында да юлъязма жанрының үсеше ике юнәлештә күзәтелә. Бер якта А.Н.Радищевнең “Петербургтан Мәскәүгә сәяхәт”е торса, икенче якта Н.М.Карамзинның “рус сәяхәтчесе хатлары” традицияләрен дәвам итү юнәлешендә язылган П.Сумароков, В.Измайлов, П.Макаров юлъязмалары бар.

Татар әдәбияты тарихында да әлеге жанрда язылган әсәрләр байтак. Мортаза бине Котлыгыш әс-Симети, Исмәгыйль Бикмөхәммәд улы, Мөхәммәд Әмин сәяхәтнамәләре шундыйлардан. Тарих XIX йөзгә аяк атлау белән бу жанр тагын да активлашып китә. Моның төп ике сәбәбен аерып күрсәтергә мөмкин: беренчедән, дәүләт хезмәтендә торган татарлар төрле илчелек составында чит илләрдә еш булалар, Россия, Төркия, гарәп илләре аша хаҗ сәфәрләре кылалар; икенчедән, сәяхәтнамә Яңарыш хәрәкәте белән кергән мәгърифәтчелек идеяләрен киң җәмәгатьчелек алдына кую өчен иң кулай жанр булып чыга, ягъни ул барлык асылы белән мәгърифәтчел максатларга хезмәт итә. Аның бу сыйфаты XIX йөз татар сәяхәтнамәләренең үсеш юнәлешен билгеләүдә мөһим роль уйный. Әлеге жанрның характерлы үрнәкләреннән саналучы Әбелмәних Каргалый сәяхәтнамәсе (“Тәрҗемәи Хаҗи Әбелмәних...”, 3нче хикәят, 1845), Гали Чокрыйның “Хаҗнамә”се (1874), Шиһабеддин Мәрҗанинең “Рихләт әл-Мәрҗани” (“Мәрҗани сәяхәте”, 1880), Заһир Бигиевнең “Мавәраэннәһердә сәяхәт” (“Ике елга арасында сәяхәт”, 1893), Фатих Кәриминең “Аурупа сәяхәтнамәсе” (1902) һәм башка юлъязмалар – болар барысы да традицион юнәлештә туган әсәрләр. Аларда тарихи, этнографик, географик фактлар автор позициясен ачык билгеләүгә хезмәт итә.

XIX гасыр сәяхәтнамәләрен идея-тематик яктан күзаллаганда аларның асылын тәшкил итүче берничә төп мәсьәләне аерып чыгарырга мөмкин. Беренчедән, барлык юлъязмаларда да төп урынны белем, мәгърифәт мәсьәләләре, шуңа бәйле рәвештә, теге яки бу төбәктәге культура учакларының, мәктәп-мәдрәсәләрнең узган һәм бүгенге халәтен объектив бәяләүгә омтылыш сизелә. Мәсәлән, Бохара мәдрәсәләрендәге уку-укыту тәртипләренең искергәнлеге хакында Заһир Бигиев үз сәяхәтнамәсендә болай дип яза: “Бохарада йөздән зиядә *(артык)* мәдрәсә вар, у мәдрәсәләрең кач миллион вакыфлары вар, урада ун беңнән зиядә иҗтиһадлә *(тырышып)* дәрес укыр. Йа, рабби! У кадәр миллионнар, у кадәр шәкертләрең газиз гомерләре биһүдә шәйләрә *(буш әйберләргә)* сарыф улыныр, хараб улыр! Боннан зиядә тәәссефле *(үкенчле)* бер хәл ула белерме?” Мәгърифәтче язучы моның

сәбәпләрен мәдрәсә мөдәррисләренең аң-белемнәре аз булуда, уку-укыту системасының искергәнлегеннән күрә.

Сәяхәтнамәләрдәге икенче төп мәсьәлә – язучы үз сәфәрендә күргән ил һәм шәһәрләр, аларның дөнья тарихында тоткан урыны; халыклар язмышы, аларның тормыш-көнкүрешләре, гореф-гадәтләре, аерым тарихи шәхесләр эшчәнлеген яктырту. Барлык сәяхәтнамәләрдә дә диярлек, иҗтимагый, тарихи, географик мәсьәләләргә бәйле фикерләр ватанпәрвәрлек идеяләре белән бергә үрелеп бара, ватанга мәхәббәт, аны сагыну мотивы көчле яңгыраш ала. Мәсәлән, Әбелмәних Каргалый туган илен сагынып:

Шәүкы мәскин китмәс ирмеш күлли хин,
Газме рәҗгать әйләмешем бәгъде зин.
Зира, имандин ирер хөббе ватан,
Дәрд илә кидәр үләнчә мәрд вә зан.

Тәрҗемәсе: *Ватанны сагыну һич китмәс күңелдән,*
*Соңгы чиктә кайту уена килдем.*
*Чөнки, ватанны ярату – иман ул,*
*Ир һәм хатын, үлгәнче, шул хис белән яшәр,*-

дип яза, туган илгә мәхәббәт хисен иманга тиңли. Ватанны сөю, аны данлау мотивы Гали Чокрыйның “Хаҗнамә”сендә, Заһир Бигиевнең “Ике елга арасында сәяхәт” юлъязмаларында да ачык сизелә.

Сәяхәтнамәләрдәге өченче төп мәсьәлә – милли, әхлакый проблемаларны ачыклау, аларны хәл итү юлларын күрсәтү. З.Бигиев, Ф.Кәрими үз әсәрләрендә татар милләтенең әхлакый сыйфатлары, белем дәрәҗәсе, бүгенге һәм киләчәк язмышы хакында фәлсәфи уйлануларына урын бирәләр. Мондый уй-фикерләр мәгърифәт, милли прогресс, гомумкешелек идеяләре белән тыгыз үрелеп бара. Шулай ук хатын-кыз азатлыгы, аның җәмгыяттәге урыны – сәяхәтче язучыларны борчыган сорауларның берсе. З.Бигиев үз әсәрендә, үрнәк итеп, төрекмән хатын-кызларын күрсәтә, аларның чагыштырмача ирекле булуларын күреп: “һәр әмердә бәдәви, вәхши улыныр төрекмәннәр мәдәни Яурупаи гаҗиз идән “хатыннар мәсьәләсе”не гаять садә, гаять асан сурәттә хәл ителмешләрдер”, - дип яза. Автор фикеренчә, хатын-кызның ирекен чикләүче төп сәбәп – аларның гыйлем-мәгърифәттән мәхрүм булуларында. З.Бигиев милләт тәрәккый итсен, хөр яшәсен өчен, мәгърифәтле булу гына җитми, азатлык өчен фидаиләрчә көрәшергә кирәк дигән идеяне дә уздыра.

XIX йөздә иҗат иткән сәяхәтче әдипләрнең максатлары бер булуга карамастан, сурәтләү алымнары ягыннан алар бер-берсен кабатламыйлар. Хәтта бер үк җирләрне тасвирлаган өлешләрдә дә һәр язучының үз стиле, үз фикер сөреше аерылып тора. Мәсәлән, Фатих Кәрими “Аурупа

сәяхәтнамәсе”ндә Кара диңгезне: “Кара диңгезгә чыктык. Босфорның туле *(озынлыгы)*, тәкърибән *(якынча)*, егерме җиде километр вә гамикъ мөтәвассыты *(уртача тирәнлеге)* егерме җиде метр, вә киңлеге биш йөз илле метр илә өч мең метр арасындадыр”,- дип коры фактларга таянып сурәтләсә, Гали Чокрый күргәннәрен хис-тойгылар аша тасвирлый: “...бәгъзе көннәрдә диңгез ярына барып карап торыр идем. Һичбер көймә вә кораб көтмәенчә китеп барырдай булыр идем. Вә ләкин Кара диңгез кара аждаһа кеби дулап торыр иде. Катнар-катнар таглар кеби аунап килгәндәй булып күренеп торыр иде. Вә һәм бер артып, бер кимеп торгандай булып, бер кабарып, бер батып торгандай булып, бер якты, бер караңгы булып кыймылдап торгандай булып күренеп торыр иде. Уңга, сулга, алга таба ни кадәр текәлеп карасаң, һаман ниһаяте күренмәс иде. Бөтен дөньяны су алган икән, моның бер-бер ниһаяте бармы икән?- диеп торыр идем”.

XIX гасырдагы сәяхәтнамә жанры хакында сүз йөрткәндә, аларның кайбер үсеше үзенчәлекләре турында әйтми мөмкин түгел. Арадан иң мөһиме – бу жанр кысаларында туган әдәби ядкярләрдә мактау объектының үзгәрә баруы. Элгәре чорларда иҗат ителгән сәфәрнамәләрдә мәдәни учаклар итеп Бохара яклары, гарәп илләре данланса, XIX гасыр сәяхәтнамәләрендә Россия, Европа илләренә йөз тотыла. Әлеге борылыш, Гали Чокрыйның “Хаҗнамә”се белән башланып, Заһир Бигиев, Фатих Кәрими юлъязмаларында дәвам итә. Шул рәвешле, XIX йөздә сәяхәтнамә жанры үсә, үзгәреш кичерә һәм шул ук вакытта әлеге чор татар әдәбиятын сыйфат ягыннан да яңа үрләргә күтәрә.

**Әдәбият**

1. *Чернышевский Н.Г.* Полное собрание сочинений. Т. V. / Н.Г. Чернышевский. – М., 1948. – 405 с.

***Гомәров И.Г.***

## ГАЛИ ЧОКРЫЙ ШИГЪРИЯТЕНДӘ ТАСАУВЫФ МОТИВЛАРЫ

XIX гасыр шагыйре Гали Чокрый әдәбият тарихында суфичылыкның нәкышбәндия тарикате вәкиле буларак мәгълүм. Нәкышбәндия юнәлешенең фәлсәфи җирлеген вәхдәт әш-шөһуд классик теологиясе тәшкил итә. Әлеге тарикатьнең рухи җитәкчеләреннән берсе Әхмәд Фаруки Сирхинди (1564-1624) тарафыннан пантеистик характерлы вәхдәт әл-вөҗуд теориясенә, ягъни «галәмдәге бар нәрсә дә Алла» дигән фикерләргә җавап рәвешендә канунлаштырылган вәхдәт әш-шөһуд фәлсәфәсе нигезендә «галәмдәге бар нәрсә дә Алладан» дигән караш ята.

Бу фикер әлеге мәзһәб тарафдары, XIX йөз шагыйре Гали Чокрый әсәр-